Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге составына керүче
Казаклар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

16 ноябрь 2023 ел № 9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 16 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Казаклар авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Казаклар авылындагы суэтем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга;
- авыл җирлегенең Казаклар авылы торак пунктында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга;
- Казаклар авылы торак пунктында урамнарның юл йөрү өлешен кышын карап торуга (кардан чистартуга); -
-суэтем башнясы өчен эшермә (задвижка) сатып алу, аны урнаштыру, артезиан скважинасыннан алып Казаклар авылындагы су башнясына кадәр суүткәргечне ремонтлауга.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 99 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 70 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 70 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Казаклар авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Казаклар авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Казаклар авылындагы суэтем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга;
- авыл җирлегенең Казаклар авылы торак пунктында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга;
- Казаклар авылы торак пунктында урамнарның юл йөрү өлешен кышын карап торуга (кардан чистартуга);
  -суэтем башнясы өчен эшермә (задвижка) сатып алу, аны урнаштыру, артезиан скважинасыннан алып Казаклар авылындагы су башнясына кадәр сууткәргечне ремонтлауга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы: Мингалеев И.Н.

СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000235 ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ